Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче
гомуми урта белем бирүче 5 нче мәктәбе

# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ «ФРОНТОВИКЛАР» ӘСӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

**Төзүче: Әхмәтгалимова Илүзә**
**9 “А” сыйныфы укучысы**



КАЙБЕР КЕШЕЛӘР ДӨНЬЯДАН КИТКӘНДӘ ҮЗЛӘРЕ БЕЛӘН БӨТЕН БЕР ХАЛӘТ- ЯШӘЕШНЕ АЛЫП КИТӘЛӘР, УЛ КЕШЕ ЯШӘГӘН ТИРӘЛЕК ОЗАК ЕЛЛАР БУЕНА ЯТИМ КАЛА

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ.

ПРОЕКТНЫҢ ПРОБЛЕМАСЫ: РУС МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ УКУЧЫ ТАТАР БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛГАН ДӘРЕСЛЕКЛӘРДӘ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ИҖАТ ҮРНӘКЛӘРЕ АЗ КҮЛӘМДӘ ӨЙРӘНЕЛҮ.

МАКСАТ:
МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ «ФРОНТОВИКЛАР» ӘСӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ ЭЧКЕ МӘГЪНӘСЕН, СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫН, ОБРАЗ ТУДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН КҮРСӘТҮ.

БУРЫЧЛАР :
- М. МӘҺДИЕВНЕҢ ИҖАТЫНА КАГЫЛЫШЛЫ ЧЫГАНАКЛАРНЫ ӨЙРӘНҮ, ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ИДЕЯ-ЭСТЕТИК КЫЙММӘТЕН АЧЫКЛАУ, ЯЗУЧЫНЫҢ ӘСӘРЕН ИГЪТИБАР БЕЛӘН УКЫП ЧЫГУ;
- ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘР ТУРЫНДАГЫ ТЕОРЕТИК МАТЕРИАЛНЫ ӨЙРӘНҮ, «ФРОНТОВИКЛАР» ӘСӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ ТУПЛАУ ҺӘМ АНАЛИЗЛАУ.

ФӘННИ ЭШНЕҢ ОБЪЕКТЫ:
ЯЗУЧЫ М. МӘҺДИЕВНЕҢ «ФРОНТОВИКЛАР» ӘСӘРЕНДӘГЕ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫ АНАЛИЗЛАУ.

ФӘННИ ЭШНЕҢ ПРАКТИК ӘҺӘМИЯТЕ:
УКУЧЫЛАРГА, СТУДЕНТЛАРГА, УКЫТУЧЫЛАРГА КУЛЛАНУ ӨЧЕН ЯРДӘМЛЕК БУЛА АЛУЫ.

# М.МӘҺДИЕВНЕҢ

# ТОРМЫШ  ЮЛЫ

М МӘҺДИЕВ 1930 ЕЛНЫҢ 1 ДЕКАБЕРЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ГӨБЕРЧӘК АВЫЛЫНДА ҖИДЕНЧЕ БАЛА БУЛЫП, ДӨНЬЯГА КИЛӘ.

ӘТИСЕ 1918 ЕЛГА КАДӘР МУЛЛА, 1930 ЕЛГА КАДӘР АВЫЛ МӨГАЛЛИМЕ БУЛЫП ЭШЛИ. 1938 НЧЕ ЕЛДА "ХАЛЫК ДОШМАНЫ" ДИП АТЫП ҮТЕРЕЛӘ.



ФОТОСУРӘТТӘ УҢНАН БЕРЕНЧЕСЕ-ЯЗУЧЫНЫҢ ӘТИСЕ



МӨХӘММӘТ ӘНИСЕ ҺӘМ ТУГАННАРЫ БЕЛӘН





БУ ӨЙ - АНЫҢ ТУГАН ЙОРТЫ.
УЛ 1916 НЧЫ ЕЛДА САЛЫНГАН.



ЯЗУЧЫ ХАТЫНЫ ЛИЛИЯ БЕЛӘН

ЯЗГЫ ДЕМОНСТРАЦИЯ. ЯЗУЧЫ ХАТЫНЫ ЛИЛИЯ ҺӘМ КЫЗЫ ГӘҮҺӘР БЕЛӘН





МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ХАТЫНЫ ҺӘМ БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН

# МӨҺӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ

# ИҖАТЫ

ЯЗУЧЫНЫҢ ”ФРОНТОВИКЛАР”,”КАЗ КАНАТЛАРЫ”, „МӘҢГЕЛЕК ЯЗ” РОМАННАРЫ , ”БЕЗ- КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ”, “ УТ ЧӘЧӘГЕ”, “ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ”, ”КЕШЕ КИТӘ- ҖЫРЫ КАЛА” ПОВЕСТЬЛАРЫ АНЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ҺӘМ ТАЛАНТЛЫ ПРОЗАИК ИТЕП ТАНЫТТЫ.

М.МӘҺДИЕВНЕҢ БАРЛЫК ӘСӘРЛӘРЕ ДӘ ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ БЕЛӘН СУГАРЫЛГАН. АЛАР БЕЗНЕҢ РУХИ МИРАСЫБЫЗ, РУХИ ЯДКАРЕБЕЗ БУЛЫП , КИТАП БИТЛӘРЕНӘ КЕРЕП КАЛГАННАР. УЛ МИЛЛИ ЙӨЗЕБЕЗНЕ АЧУЧЫ БУ МАТУРЛЫКЛАРНЫ САКЛАП КАЛЫРГА , АНЫ ҺӘР КИТАП УКУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ТҮРЕНӘ ҖИТКЕРЕРГӘ ТЫРЫША.

М.МӘҺДИЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТУГАН ХАЛКЫБЫЗНЫҢ

БЕТМӘС- ТӨКӘНМӘС РУХИ МӨЛКӘТЕ ТӘҢКӘЛӘП-ҖАЙЛАП САЛЫНЫП КУЕЛГАН. БУ ОЛЫ ИҖАТКА СОКЛАНМЫЙ МӨМКИН ТҮГЕЛ.

# Хезмәтне язу барышында кулланылган әдәбият








# Әсәрдәге фразеологизмнарга мисаллар:

- Бездә ике кешенең берсе-фронтовик. **Баскан җирдән ут чыгаралар.**
- Менә сездәй укыган кеше белән **бер утыру – бер гомер.**
- Син учуный шул, безнең кара баш белән сөйләшүе сиңа **ике тиен бер акча**.
- Дөньяда укытучыныкы кадәр бирәүнең дә **җанында казынмыйлар.**
- Сугыш кешеләрнең тормышын җимергән, **чыгырыннан чыгарган.**

# Әсәрдәге фразеологизмнарның төркемчәләре

- 1) фразеологик нығымалар
- 2) фразеологик берәмлекләр
- 3) фразеологик тезмәләр
- 4) әйтем белән мәкаль арасында тора торган арадаш төрләр

МӘҺДИЕВ ТЕЛЕ -МИЛЛИ БАЙЛЫГЫБЫЗ. АНЫҢ СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ПАЛИТРАСЫ, ТЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ БЕЛӘН КАБАТЛАНМАС ВӘ ТУТЫКМАС КӨЗГЕБЕЗ ТҮГЕЛМЕ?

АНЫҢ ТЕЛЕ - ИЛҺАМ ШАКИРОВНЫҢ МӘШЪГУР ТАВЫШЫ, РӨСТӘМ ЯХИННЫҢ МУЗЫКАЛЬ ФАНТАЗИЯСЕ КЕБЕК СИРӘК ОЧРЫЙ ТОРГАН МИЛЛИ БАЙЛЫГЫБЫЗ.






ЯЗУЧЫ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ КАБЕР ТАШЫ

ИГЪТИБАРЫГЫЗ
ӨЧЕН
ЗУР РӘХМӘТ!